Чыганак: **Фатыйма Ильская (1902-1984) : Күренекле артистка Фатыйма Ильскаяның тууына 100 ел тулуга багышланган метод.һ.библиогр. ярдәмлек / Татар.Милли к-ханәсе; Төз.Ч.Г.Яруллина. - Казан : Милли китап, 2002. – 20 б.**

# “Фатыйма Ильская – сәхнәбез горурлыгы”

*(Истәлек кичәсе.*
*Аны 2 кеше алып бара)*

**1 алып баручы.** Татар театр сәнгатендә якты эз калдырган күренекле артистка Фатыйма ханым Ильскаяның тууына 100 ел тулуга багышланган истәлек кичәбезне башлыйбыз.

**2 алып баручы.** Үзенчәлекле талантка ия булган, татар милли театр сәнгатен оештыруны башлап йөргән кешеләрнең берсе, – Фатыйма Салих кызы Ильская (Хуҗасәетова) 1902 елның 31 декабрендә Оренбург шәһәрендә туа.

“...*Миңа балачагымны искә алу авыр. Чөнки шат, якты балалык еллары миңа таныш түгел. Балачагымны гел караңгылык эчендә күрәм. Мәсәлән, менә болайрак итеп: ...Оренбург. Вокзал янындагы кечкенә генә йорт. Ул йортны землянка дип атасаң дөресрәк булыр. Йортыбыз янында – ниндидер төзелеш, тирә-юньдә йомычкалар. Мин йомычкалар җыям. 12 яшькә кадәр гел бик күп капчык була иде. Бабам Галимҗан, әбием Гобәйдә үз гомерләрен капчык арасында уздырганнар. Бабам - тегермәндә йөк ташучы иде, әбием исә - капчыклар ямаучы. Әти, әниемне хәтерләмим. Сукыр лампа яктысында әбием, бабам алар турында җай гына, матур гына итеп сөйлиләр иде. Әнием Һиҗәстә Оренбургта туган. 15 яшендә аны кияүгә биргәннәр. Төскә бик чибәр булган минем әнием, зифа гәүдәле. Әтием Салих та матурлыгы белән кешеләрнең игътибарын үзенә тарткан. Ул кара эшче булган. 25-26 яшьләрендә, ничектер, эш эзләп киткәнме, Кара диңгез буенда үлгән. Мин әтиемнән 9 айлык чагымда калганмын. Әнием күкрәк бакасыннан (йөрәк авыруыннан) үлгән. Ул үлгәндә миңа яшь ярым булган.*

*8 яшьтә, мәктәпкә керәсе урында, мин җиңгәм белән бергә эшкә йөри башлыйм, йон ташыйм. Оренбург байлары Мәхмүд, Әхмәт һәм Гани Хөсәеновлар сарык, кәҗә тиресе, йон җыеп, аларны эшкәртеп, зур сәүдә алып баралар. Аларның йон юу өчен зур корылмалары – Оренбург янындагы елганың икенче ягында, фабрика сыман бина иде. Анда йөзләгән хатын-кыз, бала-чага мәш килә. Гади халык аны мойка дип йөртә.*

*Менә шунда – мойкада, йон юам, йон ташыйм. Иртәнге 6 дан кичке 6 га кадәр.*

*Тагын шуны хәтерлим: бабам мине җәйләрен үзе белән далага, казакъ авылларына алып китә иде. Ул эшли, ә мин иксез-чиксез казакъ сәхрәсе буйлап чабып йөрим... Кычкырып көләм. Далада тавышым матур булып яңгырый. Аның яңгыравы мине тагын да куандыра, ярсыта. Тавышымның үзенчәлеге, бәлкем, әнә шул далада чарлангандыр, чыныккандыр.*

*12 яшьтә Зурлар мәктәбенә, ул заманда оренбурглылар әйткәнчә, "Воскресенская школа"га рус мәктәбенә йөрим. Русча укырга, язарга өйрәнәм..."* – дип яза Фатыйма Ильская үзенең истәлекләрендә.

**1 а.б.** Фатыйма Ильская ундүрт яшьлек үсмер кыз чагында татар сәхнәсенә килә. Ул беренче мәртәбә тамашачылар алдына 1915 нче елда Оренбург шәһәрендә чыга. Яшьлегенә карамастан, ул инде буйга җиткән туташ була. Уртачадан биегрәк сылу гәүдәсе, чем-кара озын чәч толымнары, аз гына тулырак, бик чиста ак йөзе, нечкә кашлары һәм күтәрелебрәк торган керфекләре арасыннан гел елмаеп караган кечерәк тере күзләре аның теләсә нинди яшь героиня роленә яраклык булуын әйтеп торалар.

Менә шундый чагында Фатыйманың яшь, нәфис тавышы беренче мәртәбә Фатих Әмирханның "Тигезсезләр" драмасыннан Рокыя ролендә яңгырый. Һәм бу нәкъ автор күрсәтергә теләгән, күбәләктәй җилбәзәк, назлы, сөйкемле чын Рокыя була.

Ятимлектә үскән Фатыйма үзенең тормыш тәҗрибәсе белән бай сәүдәгәр кызы Рокыядан никадәр ерак торса да, гаҗәеп бер сизгерлек белән, Фатих Әмирхан хыял иткәнчә, татар кызларына үрнәк булырга тиешле милли туташ-гимназистка образын әнә шулай ышандырырлык итеп тудыра ала.

*Фатих Әмирханның "Тигезсезләр" драмасыннан бер күренеш.*

**Рокыя.** Сөләйман абый, мин сезне шулкадәр яхшы сөйләшеп утырган җирегездән аердым бугай.

**Сөләйман.** Зарар юк! Бүген көндездән бирле мин сине күргәнем юк, мин инде сине сагынган идем, Рокыя.

**Рокыя** *(җитез генә).* Дөрес түгел, дөрес түгел, Сөләйман абзый! Сез бүген көне буе Гөлчиһрә ханым белән булдыгыз бит. Безгә килеп тә карамадыгыз. Вообще, сез соңгы көннәрдә Гөлчиһрә ханым белән...

**Сөләйман** *(көтеп торып)...* Гөлчиһрә ханым белән... аннан соң, Рокыякәй? Аннан соң?

**Рокыя** *(тавышын басып).* Бик дусландыгыз! Гөлчиһрә ханымны мин бер бүген генә сезнең балконыгызда ике мәртәбә күрдем.

**Сөләйман.** Шул бер бүген генә күргәнсең дә син аны. Ул бүген минем дача хуҗаларым белән буталып чыкты.

**Рокыя** *(җитез генә).* Мин сезне көнләшәм аннан, Сөләйман абзый!

**Сөләйман** *(көлеп).* Рокыя, синме бу? Чәченә чал кергән Сөләйманны?..

**Рокыя.** Мин синең аның белән болай дус булуыңны теләмим, мин көнләшәм.

**Сөләйман** *(гаҗәпләнгән тавыш белән).* Рокыя?.. Рокыя, көнләшү өчен сөяргә, сөйгәндә дә, хосусый бер көнләштерә торган итеп сөяргә кирәк бит. Сөләйманны, шул чәченә чал кергән Сөйләйманны сөяргә...

**Рокыя** *(уйланып).* Шул, чәченә чал кергән Сөләйманны? Ник? Аны сөяргә ярамыймыни миңа, Сөләйман абзый?

**Сөләйман** *(акрын гына).* Ярамый шул. *(Тавышын күтәрә төшебрәк).* Ярамый шул, Рокыя.

**Рокыя** *(уйчанрак).* Ул башка берәүне сөяме? Ул Гөлчиһрәне сөяме?

**Сөләйман** *(тиз генә).* Юк сөйми, Рокыя! Ул Рокыяне үк сөя, ләкин Рокыягә аны сөяргә ярамый!.. Алар артык тигезсезләр, Рокыя! *(Кинәт башын Рокыяның иңбашына куя, берәр минут шул хәлдә кала. Аннан соң кинәт башын күтәрә дә).* Бүген булмаса, иртәгә сүнәргә тиешле кешеләрне терелтергә кирәкми, Рокыя. Алар тыныч сүнсеннәр...

**Рокыя** *(акрын тавыш белән).* Мин сөям, Сөләйман абзый, шул чал чәчләрне сөям!

**Сөләйман.** Син минем кызым булырлык бит, Рокыя!.. Юк, Рокыя, син яңлышасың, син сөймисең дә, сөяргә дә тиеш түгел. Чәченә чал кергән кешеләр сөелер өчен кечкенәрәк кешеләр инде алар. Син миңа яшьлекне икенче мәртәбә кайтарма инде, ул озакка бармас барыбер. Аның белән икенче мәртәбә

аерылышу әүвәлегесеннән дә авыр булыр... Синең яшь, ялкынлы тойгыларың барыбер, кайчан да булса, үз каршыларында шундый ук куәтле яшьлекне күрергә теләрләр... Мин, Рокыя, әле дә синең белән бу ел очрашуыбыздан башлап бик күп яшәрдем... Алар өчен дә мин сиңа бурычлы.

**Рокыя** *(акрын тавыш белән)*. Мин бу сүзләрне аңламыйм, Сөләйман абзый.

**Сөләйман.** Аңламассың шул, Рокыя. Бәхетле яшьлек бу сүзләрне аңламаска тиеш! Ләкин ул сүзләр сиңа никадәр аңлашылмаслык булсалар, миңа шулкадәр үк аңлашылалар. Менә шунда минем бөтен бәхетсезлегем дә.

**Рокыя.** Сез минем үзегезне сөюмне теләмисез? Сез миңа рөхсәт итмисез?

**Сөләйман.** Әстәгъфирулла, Рокыя.. Ни дигән сүз алар? Сөюемне теләмисез, рөхсәт итмисез дигән сүзләр – болар синең күз ягылдыргыч матур яшьлегеңә ягышмый торган сүзләр. Син минем белән сөйләшкәндә андый сүзләр әйтмә, Рокыя.

**Рокыя.** Мин шулай уйладым, Сөләйман абзый.

**Сөләйман.** Син, Рокыя, минем үзеңне сөйгәнлегемне бик яхшы беләсең. Аны син үзең генә түгел, бу дачадагы бөтен кешеләр дә беләләр бугай инде. Мин аны мондагы бөтен кешеләрнең хәйләле елмаюларыннан аңлыйм. Минем күзләрем генә түгел, сүзләрем дә син булган җирдә чәчемә аралашкан чалларны оныта башлыйлар... *(Кинәт бүлеп)* Ну, ярый, куйыйк бу тугрыда сөйләшүне, Рокыя.

**Рокыя** *(Сөләйманның сүзләрен тыңламагансымак, җәһәт кенә, катгый гына)*. Мин сезнең Гөлчиһрә ханым белән болай якын булуыгызны теләмим, ул бер сөйгән инде, аның икенче сөяргә хакы юк. Ул – кеше хатыны, сезнең дә аны сөяргә хакыгыз юк, аның баласы бар...

**Сөләйман.** Тынычлан, Рокыя! Синең хыялың артык бай, үзең уйлап кына чыгарган бер нәрсә өчен шулкадәр кызу сүзләр сөйлисең. Гөлчиһрә миңа ике ай бер дачада торып ияләнешкән белешләрдән булган бер белеш. Мин аңар – аның җанының авырта торган җиренә бер дә кагылмыйча, сөйләп утыра белүче мосахипләрдән бер мосахип. Менә сиңа безнең аның белән булган бөтен мөнәсәбәтебез. *(Кинәт сүзен бүлеп.)* Рокыя, җаным бул, куйыйк бу тугрыда сөйләшүне... Син минем үзеңне сөйгәнемне белмә; мин синең, минем чал чәчләремне дә гафу

итәргә хәзер икәнеңне белмим. Шуларны белешкән минуттан безнең икебезгә дә җәһәннәм булыр. *(Җәһәтләнеп.)* Мин сине, Рокыя, шул минуттан чәчләренә чал кермәгән бөтен кешеләрдән көнләшә башлармын, мин сине газапрармын, үзем синнән артыграк газапланырмын! Ишетәмсең, Рокыя! Икебез өчен дә җәһәннәм булыр. *(Сүзен аз гына кисеп торып, башын скамья аркасына таянып куйган кулы астына атып.)* Ник, Рокыя, бу сүзләрне әйттердең син миннән? Болар минем серләрем иде. Мин боларны әйтергә теләмидер идем. Бу нәрсәләрне мин үзем генә белеп торырга, берәүгә дә, берәүгә дә әйтмәскә, бигрәк тә сиңа әйтмәскә тиеш идем. *(Башын күтәреп.)* Фәрештәм бул, Рокыя, куйыйк хәзер бу мәсьәләне! Теләсәң, аны икенче бер мәртәбәдә сөйләшербез, миңа хәзер авыр...

**Рокыя.** Бераздан, Сөләйман абзый, ярыймы?

**Сөләйман.** Син теләгән вакытта, Рокыя! *(Бераз сәктә ясап, тавышын үзгәртеп.)* Рокыя, син намаз укыймсың?

**Рокыя.** Ник аны сорыйсың, Сөләйман абзый? Намаз укырга ярамыймыни?

**Сөләйман.** Болай гына, Рокыя... Беләсем килә, ник ярамасын!

**Рокыя.** Бәйрәм кичләрендә укыйм. Нигә инде ул, Сөләйман абзый, сиңа?

**Сөләйман.** Ник бәйрәм кичләрендә генә?

**Рокыя.** Мин бәйрәм кичләрендә әтигә Коръән укыйм... Әти, мәрхүм, миңа үзе үләр елны плюш белән тышланган бик матур Коръән алып кайтып биргән иде. Аның язуы да бик матур, бу басма Коръәннар шикелле түгел...

**Сөләйман.** Коръән укыр алдыннан намаз укыймсың?

**Рокыя.** Шулай итәм шул... Анысы нигә иде, Сөләйман абзый, сиңа?

**Сөләйман.** Мин бервакыт синең намаз укыганыңны карап тормакчы булам.

**Рокыя.** Ай, юк, юк, Алла хакы өчен, юк, Сөләйман абзый. Мин бүлмәмне бикләп куям, ул вакытта бер кешене дә кертмим. Мин кеше карап тора торган җирдә намаз укый белмим, бервакыт бикләнмичә намаз укырга тотынып, бүлмәмә әни кергән иде дә, анда да намазым намаз булмады, ахырдан әтигә Коръән да укымадым.

**Сөләйман.** Син намаз укый торган бүлмәгә нур иңә торгандыр шикелле, Рокыя, бәлки, синең белән бергә

фәрештәләр дә намаз укыша торгандыр...

**Рокыя.** *(җәһәт кенә).* Сез көләсез, Сөләйман абзый! Әгәр мин гыйбадәтләрдән көлә торган кеше булсам да, синең гыйбадәтеңнән көлә алмас идем, син аңар сәҗдә итә торган Алланың җәмалы алдында мин дә муенымны бөгәр идем... Мин үзем дә, матур айлы кичләрдә ялгызым гына утырган чакларда, Алла хакында уйланырга яратам... Мин сине намаз укыган чагыңда күрәсем килә, Рокыя! Мин әле бала вакытымда әниемнең, апаларымның намаз укыганнарын күрә идем, ләкин алар укый белмиләр иде... Син укый белә торгансыңдыр, Рокыя, син аны матур итеп укый торгандырсың, синең күзләрең дә Аллага сәҗдә итә торганнардыр... Минем күрәсем килә.

**Рокыя.** Ай, юк, юк, Сөләйман абзый, Алла хакы өчен, юк. Мин кеше күргәнне яратмыйм, кеше алдында укый белмим!

**Сөләйман.** Мин кайчан да булса синең намаз укыганыңны бер күрермен. Син үзең аны белмәссең дә. *(Бераз торып.)* Син әле, Рокыя, минем хикәям өчен ясамакчы булган рәсемнәреңне ясый башладыңмы?

**Рокыя.** Берсен бетердем инде! Үземчә, анысы яхшы да чыкты. Галиеңнең күз карашында көнләшү белән ачу катыш бер нәрсә чыгара алдым шикелле. Зәйнәбеңнең икенче кулы ул вакытта ничек торганлыгын син язмыйсың бит анда; мин үземчә, үз хыялым белән, ул кулына бер килеш бирдем; дөрес биргәндерменме инде, юкмы, анысын белмим. Минемчә, ул хәлдә шулай булырга гына мөмкин.

**Сөләйман.** Менә аны карыйбыз инде. Әгәр минем башымдагыча чыгара алган булсаң...

**Рокыя** *(бераз көтеп торып, шаян гына)* ... Мин синең кулыңны үбәрем димәкче идеңме әллә, Сөләйман абзый?

**Сөләйман.** Теләр идеңме?

**Рокыя** *(җитез генә).* Ник теләмәскә, хезмәт бәрабәренә бит!

**Сөләйман.** Бер генә түгел, өч мәртәбә, Рокыя!

**Рокыя.** Мин ул хикәягезне, Сөләйман абзый, шулкадәр яраттым. Шулкадәр яраттым...

**Сөләйман.** Яраттыңмы? Син үзең илһам иткән хикәя ул, Рокыя. Аны миңа синең күзләреңнең бер иркә елмаюлары илһам итте. Шуңар күрә дә ул шундый җиңел, шундый очынып тора торган булып чыкты.

**1 а.б.** 1916 нчы елның көзендә, Кариев чакыруы буенча, Фатыйма Казанга, "Сәйяр" труппасына килә. Бирегә килгәч тә, аның Казан тамашачыларына уйнап күрсәткән роле шул ук Рокыя була. Шуны истә тотарга кирәк: "Тигезсезләр" Казан сәхнәсендә 1915 нче елда ук куела, ләкин әсәрнең төп героинясын бирәү дә уңышлы башкарып чыга алмый. Инде Фатыйма уйнагач, Казанның тамашачылары да, вакытлы матбугаты да бертавыштан; "Менә бу, ичмасам, чын Рокыя!" – диләр. Әсәрнең авторы Фатих Әмирхан яшь артисткага үз кулы белән чәчәкләр бүләк итә. Кариев белән Тинчурин Фатыйманы "Ил кызы" дип атыйлар, менә шуннан аның сәхнә фамилиясе Ильская булып китә.

Шулай итеп, Фатыйма Ильскаяның нинди зур талантка ия икәнлеге беренче чыгышыннан ук шактый тулы булып ачыла, татар сәхнәсе аның йөзендә кабатланмас, үзенчәлекле артистканы таба. Шуның белән бергә, Рокыя образы Ильскаяның алдагы иҗат юлына ничектер якты бер нур булып төшә, һәм яшь артистка, гүя, шул юлдан кыю, батыр адымнар белән осталык биеклегенә, алда көткән шөһрәтенә таба атлап китә.

**2 а.б.** Чынлап та, Фатыйма Ильская гаҗәеп бер тизлек белән үсә башлый, еллап түгел, айлап уңышлардан уңышларга ирешә бара. Казанга килүенә берничә ай үткәч тә, аның бенефисы булып, шул уңай белән француз драматургы Геның "Трильби" дигән әсәре куела. Фатыйма төп героиня Трильби ролен башкара һәм, озак та үтми, "Аң" журналында Габдрахман Кәрам: "*Ильская Трильби ролен көткәннән артык яхшы уйнап, халыкның күп алкышларына мәзһәр булды*", - дип язып чыга.

Бу уңышларның сәбәбе нәрсәдә булган соң? Әлбәттә, моның иң беренче төп сәбәбе – яшь артистканың зур талантка ия булуында.

Бу талантның Фатыйма Ильскаяга гына хас үзенчәлекләре нидән гыйбарәт соң? Иң элек ул тирән эчке сизгерлеккә – интуиция көченә — үзенең гаҗәеп бай булуын күрсәтте. Нинди генә рольгә алынмасын, Ильская аның җанын бик нечкә һәм дөрес тоя белә. Шунлыктан артистканың һәрбер иҗат иткән образы үзенә генә хас бөтен эчке һәм тышкы сыйфатлары белән бик табигый булып гәүдәләнә. Шуның белән бергә, Фатыйма Ильскаяда хисләр кичерешенең иркен төрләнә алуы, бу кичерешләр төрләнүен искиткеч дөрес чагылдыра белгән

**2 а.б.** Үләр алдыннан Кариев биреп калдырган сары төстәге җәүһәрле йөзекне дә К.Тинчурин хаклы рәвештә Фатыйма Ильскаяга калдырган.

Сәхнә иҗатын романтик драма героинясы буларак башлый, соңыннан да артистлык яшьлеге буяуларыннан бөтенләй үк баш тартмый ул. Классик репертуарда Ф.Ильская уйнаган кадәр татар театрында, хәер, бер татар театрында гына түгел, бер генә актриса да уйнамагандыр. Күз алдына гына китерик. Ун-унике ел эчендә – сугыш алды һәм сугыш елларында – ул Офелияне, Дездемона, Джульетта, Корделияне, Лопе де Вега, Мольер, Гольдони, Бомарше, Шиллер, Островский, Горький пьесаларында героиняларны уйный.

Ул иҗат иткән образлар, характерлар берсе берсеннән нык аерылалар. Алар — катлаулы һәм конкрет образлар. Фатыйма Ильская башкаруында аларның һәркайсы тамашачылар алдында җанлы һәм тулы канлы булып килеп баса.

Фатих Әмирхан, Гафур Коләхмәтов, Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Нәкый Исәнбәт, Таҗи Гыйззәт һ.б. әсәрләрендә, рус драматургиясе үрнәкләрендә тәрбияләнеп, иҗади чыныккан Фатыйма ханым үзенең сәхнә гомерендә йөзләрчә образлар тудырды, Көнбатыш классик драматургиясенең иң катлаулы образларын да татар тамашачыларына җиткерә алды.

Менә саф, эчкерсез, югары әхлаклы Корделия, менә тирән бөеклеген аңлаган Джульетта, Дездемона, Луиза, менә Катерина, Анечка, Елена, Татьяна, Таня. Менә Зөләйха, Камилә, көнче, үзсүзле Диана, менә зирәк Эльмира, менә үзенең матурлыгыннан файдаланып кәсеп итүче җилкенчәк Мирандолина, менә Офелия, Амалия, Сюзанна... Алар барысы да безнең күз алдыбызда басып торалар, чөнки артистка аларны тамашачы күңелендә онытылмаслык эз калдырырлык итеп иҗат итте. Сокландыргыч осталык белән эшләгән образлар аша тамашачы артистканы таныды, таныды гына түгел, алкышлады, хөрмәтләде. Ф.Ильская чын сәхнә остасы булып ватаныбызга танылды. Ул – Татарстанның һәм Россиянең халык артисткасы.

**1 а.б.** Фатыйма Ильская 1984 елның 15 ноябрендә вафат була.

**2 а.б.** Фатыйма Ильскаяның иҗат биографиясендә татар тарихына кереп калган образлар берничә дистә. Зур иҗат

тормышын кичергән, табигать тарафыннан аңа сәхнә өчен генә бирелгән гүзәллеккә, бай хисләргә ия булган, татар театры сәхнәсендә якты йолдыз булып балкыган Фатыйма Ильскаяны без бүген зур горурлык белән искә алабыз.

*Кичә тәмам.*

**Кулланылган әдәбият**


1. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1983.
2. Игъламов Р. Ил кызы // Соц.Татарстан. – 1982. – 28 февр. – Б.3.
3. Ильская Ф. Истәлекләрем // Казан утлары. – 1982. - №1. – Б.166-176.
4. Илялова И.Г. Камал театры артистлары: Биобиблиогр.белешмәлек = Артисты театра им. Г.Камала: Биобиблиогр. справ. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. – 266 б.
5. Ихсанова Л. Хезмәт һәм хөрмәт // Азат хатын. – 1982. - №2. – Б.8-9.
6. Рахманкулов Ш. Фатыйма Ильская // Совет әдәбияты. – 1956. - №7. – Б.101-105.
7. Шәрәфиев Ф. Ил кызы // Татарстан яшьләре. – 1982. – 2 март.
8. Әмирхан Ф. Сәхнә әсәрләре һәм публицистика. – Казан, 1958.
9. Җиһаншина Р. Онытылмас шәхес (Фатыйма Ильскаяның тууына 90 ел) // Соц.Татарстан. – 1992. – 11 гыйнв. – Б.3.